وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№21 (138). 25 май 2012 / 4-рәҗәп-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Халык мәдрәсәсе ▷2◁





Яңа бистәнең беренче таш мәчете ▷3◁





"Кол Шәриф оныклары"ның бишенче бәйгесе узды ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**ИСТАНБУЛ МӨФТИЕ РӘХМИ ЯРАН БЕЛӘН ОЧРАШУ УЗДЫ**

ТР мөселманнары Диния нәзарәте бинасында мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Истанбул мөфтие Рәхми Яран белән очрашты. Мөфтиләр киләчәктә дә бердәм хезмәттәшлек турында килештеләр. Очрашуда шулай ук Төркия Республикасының Казандагы консулы Әхмәт Акынты, Төркия илчелегенең Россиядәге дин эшләре буенча киңәшчесе Фәхри Саглык, Коръән хафизлар катнашты.

Делегация әгъзалары ТР мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеге белән таныштылар, шулай ук Кол Шәриф, Мәрҗани, Апанай мәчетләрендә һәм Казан ислам колледжында булып кайтты.

**ШӘҺАДӘТНАМӘЛӘР ТАПШЫРЫЛДЫ**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Нурлат, Тәтеш районы имамнарына рәсми рәвештә имам-хатыйблык шәһадәтнамәсе тапшырылды. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз район җирлекләрендә эшләүче дин әһелләрен шәһадәтнамә алулары белән котлады, изге теләкләрен җиткерде һәм бергәләп дингә хезмәт итәргә чакырды. Тантанада имам-хатыйбларга күптән түгел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте чыгарган Коръәни-Кәримнең Казан басмасы бүләк ителде.

**БӨГЕЛМӘДӘ КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ ҮТТЕ**

19 майда Бөгелмә шәһәренең җәмигъ мәчетендә мәхәллә халкы арасында районара Коръән укучылар бәйгесе үткәрелде. Бәйгене Бөгелмә районы мөхтәсибәте һәм Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казыяте оештырды.

Бәйге Бөгелмә, Ютазы, Баулы һәм Лениногорск районы мөселманнары арасында үткәрелде. Азнакай һәм Әлмәт районнарыннан да вәкилләр катнашты.

**КАЗАН МӘЧЕТЛӘРЕНДӘ БЕР ДӘРЕСТӘ НАМАЗГА ӨЙРӘТӘЛӘР**

Казан шәһәре мәчетләре барлык мөселманнарны ислам тәгълиматы, шулай ук ислам динендәге иң әһәмиятле гыйбадәтнең берсе булган намаз укырга өйрәнергә чакыра. Бер дәрес эчендә дин әһелләре һәр мөселман кешесе белергә тиеш булган гыйлемне җиткерәчәк, намаз уку тәртибе белән таныштырачак.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте намаз укырга өйрәнергә мөмкин булган мәчетләрнең исемлеген игълан итә. Алар - Болгар, Әниләр, Дин Ислам, Шамил, Хөзәйфә, Ризван, Рамазан, Иман нуры, Мәдинә мәчетләре. Мәчетләрдә 27 майда көндезге сәгать унбердә көтеп калалар.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# ИЗГЕ АЙЛАР МӨБАРӘК БУЛСЫН!

2012 елның 21 май төнендә мөселманнар өчен изге рәҗәп ае башланып китте. Рәҗәп ае ислам динендәге изге айларның берсе. Шулай ук ул Аллаһы Тәгалә сугыш һәм талашларны тыйган дүрт айның (рәҗәп, зөлкагдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм) берсе булып тора.

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз мөселманнар өчен изге саналучы айлар турында аңлатма биреп болай диде:**

- Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү! Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде! Рәҗәп - гөнаһларны ярлыкау, якыннарың-дусларың белән аралашу һәм гыйбадәт кылу ае. Киләсе шәгъбан - мәхәббәт һәм гыйбадәт кылу ае, аннары рамазан - Аллаһы Тәгаләдән кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидиятне ачык бәян кылучы Коръән иңдерелгән ай килә. Мөхәммәд галәйһиссәләм бу өч ай турында: "Рәҗәп - Аллаһның ае, шәгъбан - минем аем, рамазан исә өммәтемнең аедыр", - дигән, һәм: "Аллаһым, безгә рәҗәп һәм шәгъбанны мөбарәк кыл һәм безне рамазанга ирештер", - дип дога кылган.

Хәзрәти Зәннүн Мәсри болай дигән: "Рәҗәп - чәчү, шәгъбан - су сибү, рамазан - җыю". Бу айда күбрәк тәүбә итәргә, гыйбадәт кылырга кирәк. Әлеге айларда гөнаһлардан нык саклану, Аллаһка гыйбадәттә булу сорала. Бу эштә кем күбрәк тырыша, шул кеше иминлек, бәхет белән бүләкләнер.

Рәҗәп ае кергәч, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) болай дип дога кылган: "Әллаһүммә бәрикләнә фи раҗәбә вә шәгъбан ва бәллигънә рамазан". (Мәгънәсе: "Ий Аллаһ! Рәҗәп һәм шәгъбан айларын безнең өчен мөбарәк кыл һәм безне рамазан аена ирештер".)

Мөхәммәд галәйһиссәләм: "Рәҗәп аеның беренче көнендә ураза тотсаң, өч еллык гөнаһлардан кәффәрәт булырсың; икенче көнендә тоту - ике еллык гөнаһлардан, өченче көнендә ураза тоту - бер ел эчендә кылган гөнаһлардан чистарта", - дип әйткән. Соңыннан һәр көн бер айлык гөнаһлардан арынуга тиң дип билгеләп үтелә.

# РӘҖӘП АЕ

## Рәҗәп - ислам динендә булган дүрт изге айның берсе.




**Бүген - Рәгаиб кичәсе көне, кичә Рәгаиб кичәсе иде (Пәйгамбәребезнең (сгв) әти-әнисе никахлашкан-кавышкан көннәр). Үзе җомга көн, үзе Рәгаиб кичәсе көне. Икеләтә бәйрәм көн бу. Җомга көнне шундый бер сәгать бар, шул сәгатьтә теләгән теләк кабул булмыйча һич калмас, ди. Менә аның кайсы сәгать икәнен бер Аллаһы Тәгалә генә белер, ди. Шуңа күрә җомга көн кояш баеганчыга кадәр зекердә булып, Аллаһы Тәгаләне олуглап, авызларыбызны начар сүзләрдән тыеп, яхшы теләкләрдә генә йөрергә кирәк.**

Без кайвакыт, үзебез дә уйламастан, балаларыбызга, туганнарыбызга, якыннарыбызга теләсә нәрсә кычкырып куябыз. Җомга көнне безнең уйламыйча әйткән сүзебезнең афәтләр китерүе бар. Балаларыбыз авырып китсә, нәрсә булды икән дип борчылабыз. Үзебезнең уйламыйча әйткән сүзләребезнең дә балаларыбызга зыян булып төшүе бар бит. Җомга көннәрендә яман гадәттән бигрәк тә сак булырга кирәк. Адәм баласының нәфесе бар, теле бар, күңелендә төрле уйлар бар. Әмма начар теләкне беркайчан да теләмәскә кирәк. Җомга көнне шушы теләкләрнең кабул була торган бер сәгатенә туры килүе бар.

Рәҗәп аенда Пәйгамбәребезнең (сгв) әти-әнисе кавышкан. Айның 27 нче кичәсендә Пәйгамбәребез (сгв) күккә ашкан, Аллаһы Тәгалә белән очрашкан. Безгә шушы көнне биш вакыт намаз фарыз булган. Кыскасы, бу айда мөселманнар тарихына, динебез тарихына бәйле әһәмиятле вакыйгалар күп. Шуңа да рәҗәп ае изге айлардан санала. Шәгъбан ае да - изге ай. Аннары изге рамазан ае килә. Шушы айлар безнең рамазан аена әзерлегебез дә булып тора. Рәҗәп аенда без инде рамазан аена чын-чынлап әзерлегебезне башлыйбыз. Нәфел уразалары тотабыз, сәдакалар бирәбез. Шулай иттереп, без күңелебезне сафлап, Аллаһы Тәгалә тарафыннан һидәят өчен, туры юлга күнәр өчен, безгә бүләк итеп бирелгән изге аена әзерләнә башлыйбыз. Изге айларда тәүбәгә килү бик саваплы. Һәркайсыбызның эшләгән гөнаһлары бар, аларны искә төшерергә кирәк. "Әстәгъфирулла"ны күп әйтергә, гөнаһларыбыздан тәүбә кылырга кирәк. Берәү, үзенең гөнаһын искә төшереп, шуңа тәүбә итсә, тәүбә кылса, үкенсә, яңадан бу гөнаһларны кабатламаса, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтүенчә, аның мондый гөнаһы кичерелгән дип санала. Димәк, безгә начар эшне эшләгәнебезгә үкенергә кирәк, тәүбәгә килеп, "Әстәгъфируллаһ" дип. Һәм инде "Кәлимәтүл истигъфар"ны әйтсәк тә бик әйбәт. (Тик соңыннан моңа кадәр эшләгән бозыклыкларны яңадан кабатламаска кирәк.) Шуңа көч табабыз икән, димәк, Пәйгамбәребез (сгв) әйткәнчә, шушы гөнаһ ярлыканган дип санала. Тәүбәгә килгәнсең икән, Аллаһы Тәгалә шушы гөнаһыңны ярлыкасын өчен шул тәүбәңә үлгәнче тугры калырга кирәк. Укылмый калган намазларыбызны, тотылмый калган уразаларыбызны да изге айларда үтәү яхшы, чөнки бу - Аллаһның рәхмәт айлары. Бу - гамәлләребезнең кабул ителә торган айлары. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Рәҗәп аенда мин ачуымны бикләп куярмын, рәхмәтем яңгыр шикелле явар", - ди. Бу изге айларда әҗер-савап йөз мәртәбә артыграк булыр. Тырышып-тырышып Коръәннән бер аять яисә бер хәреф өйрәнсәк, бер хәрефкә ун савап тияр, ди. Башка айларда бер хәрефкә ун савап була дисәк, изге айларда өйрәнгән бер хәрефебезгә мең савап та булырга мөмкин. Һәм рамазан аенда исә бер хәрефкә җиде меңгә кадәр савап була. Менә шуңа Аллаһның шундый рәхмәт айлары бар. Бу айларда, сәдака биреп, ятимнәрне, мескеннәрне, авыруларны сөендерү дә бик саваплы. Арабызда ятимнәр, авыру кешеләр, тумыштан гарип булганнар бар. Андый кешеләрнең генә түгел, үз гаиләндәгеләрнең, танышларыңның, дусларыңның да күңелен күрергә, аларга бүләкләр, сәдакалар бирергә кирәк. Хәлләрен белеп, аларны сөендерү, әлбәттә, бик тә саваплы гамәлләрдән.

Менә шушы эшләргә без шушы айларда хирыс булырга, шушыларны башкарырга гадәтләнү лазем. Бу айларда яман эшләрне куеп торырга кирәк. Рәҗәп, шәгъбан, рамазан айларында, яман эшләребезне куеп, изге эшләрне күп эшләсәк, Аллаһның безгә рәхмәте булыр. Шуннан соң без яман эшләрне, бәлки, бүтән кабатламабыз да. Телләребезне дә, күңелләребезне дә яман сүзләрдән пакьләрбез. Рәҗәп аен изге ай дип санап, аны кадерләп, Аллаһ кушканча кадерләп, әйбәт итеп үткәрергә кирәк. Шәгъбан, рамазан айларында да Аллаһы Тәгалә каршысында чиста булып, пакь булып, гөнаһларыбыздан арынып, изге гамәлләребез белән күренеп калыйк.

***Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстанның баш казые***

# ҺӘР УНИВЕРСИАДА КУНАГЫНА — ТЕЛӘГӘН РИЗЫК

**2013 елның 6-17 июлендә Казанда үтәчәк Универсиада мөселманнар өчен изге саналган рамазан аена туры килә. Шушы уңайдан дин тотучылар өчен чарада аерым шартлар булдырылачак.**

22 май көнне Татарстан Хөкүмәт йортында узган брифингта Универсиадага әзерлек эшләре белән таныштырдылар. Биредә спорт корылмалары, юллар төзү, катнашучылар өчен транспорт мәсьәләсен хәл итү, кунакларга визасыз режим булдыру һәм башка темалар турында сүз чыкты.

## Ашханәдә хәләл ризыклар була

"2013 ел Универсиадасы дирекциясе" җитәкчесе Владимир Леонов сүзләренә караганда, уеннар вакытында кунакларның дини, милли ихтыяҗлары тулысынча исәпкә алыначак. Әйтик, киләсе елга рамазан ае 9 июльдә башланыр дип фаразлана. Казанга мөселман илләреннән арбитрлар, спортчылар күп килер дип көтелә. Шуңа күрә алар өчен Универсиада ашханәсенең эш вакыты озынайтылачак.

"Бу гына да түгел, катнашучыларга берничә төр меню тәкъдим итәбез. Хәләл ризыклар, Азия, Европа халыклары ашлары, вегетарианнар өчен һәм башка төр азык-төлек булачак", - диде Владимир Леонов. Чит илдән килгән кунакларга милли тәм-томнарыбыз да тәкъдим ителәчәк. Универсиада авылында гыйбадәт кылу урыннары булдыру да төрле дин вәкилләренә карата ихтирамны күрсәтә.

## Татар теле - Универсиада теле дә

XXVII Халыкара студент уеннары Татарстанның ике дәүләт телендә (татарча, русча) һәм инглизчә алып барылачак, шулай ук башка телләргә тәрҗемә итү күздә тотыла. "2013 ел Универсиадасы дирекциясе" җитәкчесе сүзләренә караганда, тел белгечләрен инде алдан ук әзерли башлаганнар. Хәзерге вакытта республика югары уку йортлары белән шул юнәлештә хезмәттәшлек алып барыла.



Халыкара студентлар уеннары кунаклары өчен 2013 елга 5 госпиталь әзерләнә. Анда бүген медицина персоналы туплыйлар, спорт корылмалары эчендә допинг-контроль бүлмәләре төзиләр. "Русада" Россия допингка каршы агентлыгы белгечләре тарафыннан бүген допинг контроль үткәрергә 35 инспектор сайланган. Җәйге Универсиада көннәренә аларның саны 60 ка җитәчәк. "ГЛОНАСС+ 112" ашыгыч ярдәм системасына мөрәҗәгать иткән чит ил кунаклары да үз телләрендә җавап алачак.

***Миләүшә ЗАКИРОВА,***
***www.intertat.ru***

# Халык мәдрәсәсе

**20 май көнне Кукмара мәдрәсәсендә чыгарылыш мәҗлесе булып узды. Мөгаллимнәр һәм мәдрәсәне тәмамлаучы шәкертләрдән тыш, әлеге чарада Кукмара мөхтәсибәте һәм ТР мөселманнарының Дания нәзарәте вәкилләре дә катнашты.**

Җыелыш Коръән аятьләре укылып дога кылудан башланды. Район имам-мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин гыйлем алу әһәмиятенә багышланган вәгазь сөйләгәннән соң, мәдрәсә директоры Ришат Курамшин чыгарылыш сыйныфлары шәкертләре һәм мәдрәсә эшчәнлеге турында мәгълүмат бирде.

Кукмара мәдрәсәсенә 1998 елда нигез салына. Ул вакытта аның аерым бинасы, уку өчен тиешле шартлары булмый. Әмма халыкның дин белеменә сусап күпләп укырга килүе мөгаллимнәрне рухландыра һәм гыйлем бирүне бер тәртипкә салып әлеге эшне башкарырга зур этәргеч була.

Ун ел дәвамында мәдрәсә Үзәк мәчет бинасында эшли. Район мөселманнары, дин җитәкчеләре хакимияткә мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә, 2008 елда мәдрәсәнең бинасы салына башлый һәм Аллаһның олуг рәхмәте белән, нәкъ бер елдан Кукмара Үзәк мәчете янәшәсендә өч катлы күркәм бина калкып чыга.

Шартлар яхшыргач, укыту процессын камилләштерергә, төрләндерергә ниятләп, мәдрәсә коллективы махсус лицензия алуга ирешә һәм урта профессиональ дини белем бирүче кичке бүлекне ачып җибәрә. Бүген мәдрәсә, шулай итеп, халыкка 2 юнәлештә дини белем бирә: башлангыч һәм урта-махсус. Ике бүлектә барлыгы 400 ләп кеше укый, шул исәптән кичке бүлектә 80 ләп шәкерт.

Быел мәдрәсәне 127 шәкерт тәмамлады. Шуларның 29 ы ир-егетләр, 68 е - хатын-кызлар, 22 се - малайлар, 8 е - мәктәп яшендәге кызлар. 107 кеше башлангыч бүлекне тәмамласа, кичке бүлекне тәмамлаучы 20 шәкерт урта-махсус дини белем алуны раслаучы дипломнарга ия булды. Чыгарылыш сыйныфлары укучылары арасында 52 кеше - кукмаралылар, 75 кеше - район авылларыннан килеп укучылар.

Быелгы, 13 нче чыгарылыш шәкертләре санын әүвәлге елларда мәдрәсәне тәмамлаучылар санына кушсаң - 997 килеп чыга, ягъни шушы вакыт эчендә Кукмара мәдрәсәсендә меңгә якын кеше укып чыкты. Шунысы шатландыра: шактый күп авылларда әлеге уку йортын тәмамлаучылар дин дәресләре бирә. Райондагы 68 мәхәлләнең 35 ендә имам вазифаларын Кукмара мәдрәсәсендә белем алган абыйлар башкара. Быелгы чыгарылыш шәкертләре арасында да авыл имамнары бар: Шамил хәзрәт Җәләлиев (Әсән-Елга авылы), Нурислам хәзрәт Мортазин (Сәрдекбаш), Хакимҗан хәзрәт Шакирҗанов (Каенсар), Азат хәзрәт Һадиев (Бакчасарай). Шулай ук Саба районының Яулаштау авылы имамы Илнур хәзрәт Фәйзрахманов та быел Кукмара мәдрәсәсен тәмамлаган.

13 нче чыгарылыш шунысы белән дә үзенчәлекле булды: мәдрәсәне дөньяви мәктәп системасында эшләүче яки озак еллар шунда хезмәт итеп лаеклы ялга чыгучы шактый күп укытучылар тәмамлаган икән. Әйтик, Хәләветдинова Гүзәлия Шакирҗан кызы (Туембаш), Низаметдинова Раушан Гаяз кызы (Кукмара), Кочергина Нурисә Фәләх кызы (Кукмара), Шакирова Гөлтаһирә Фәйзрахман кызы (Янил), Мөхәммәтгалиева Хәлимә Мөгыйн кызы (Зур Сәрдек), Җәләлиева Миңнекәүсәрия Билал кызы (Әсән-Елга), Хантемирова Җүәйрә Абдулла кызы (Кәркәүч) шундый тәҗрибәле, талантлы укытучылардан. Мәдрәсә җитәкчелеге аларга аеруча зур өмет баглап, шушы хөрмәтле мөгаллимәләребез дин юлында да һөнәри осталыкларын файдаланырлар дигән ышанычын белдерә.



Дини гыйлем дигәндә, аның кыйммәтен аңлаган кешегә бүген, дөрестән дә, зур мөмкинлекләр ачылды. Кукмаралылар шушы мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмаска тырыша булса кирәк. Укыту программасы бер тәртипкә салынып, һәр теләгән кеше укырлык шушындый халык мәдрәсәләре кирәкме бүген? Һичшиксез, кирәк. Әлбәттә, башка кайбер җирлекләрдә кебек ел саен 15-20 кеше кабул итеп, әлеге мәдрәсә дә 50-60 шәкерт "асрап" ята алыр иде алуын, әмма алар икенчерәк юнәлешне - барлык район халкына хезмәт итү юлын сайлаганнар. Шуңа да биредә мәктәп яшендәге балалардан алып, сиксәненче дистәне вакларга тотынган әби-бабайларга кадәр укып йөри. Аеруча сөендергәне - яшьләрнең күп булуы. Уйлап карасаң, бу бит аларның ахирәткә, Мәңгелеккә әзерләнеп йөрүләре. Ә моннан да мөһимрәк эш бармы бу дөньяда?

Чыгарылыш кичәсе истә калырлык мизгелләргә бай булды. Мине генә түгел, башкаларны да иң нык тетрәндергәне, мөгаен, рус төркемендә белем алган Валентина Александровна исемле бер апаның чыгышы булгандыр. Ул биредәге мөгаллимнәрнең ихлас күңелле булуларына соклануын белдереп, бер кәлимә-сүз татарча белмәгәннәрне дә кире бормыйча гыйлем алырга мөмкинлек тудырганнары өчен олы рәхмәтен белдерде. Рус милләтеннән булган бу апа чыгыш ясаганда күпләрнең күзләреннән шатлыклы күз яшьләре атылып чыкты...

Тантаналы мәҗлес ахырында мәдрәсә директоры Ришат хәзрәт шәкертләргә киңәш-нәсыйхәтен җиткереп болай диде:

- Мәдрәсә тәмамлаган, дин белемен үзләштергән кеше тормышта башкаларга үрнәк булырга тиеш. Сезгә карап кешеләр күңелендә ислам динебез турында уңай фикерләр генә тусын. Аннары шунысы да мөһим: мәдрәсә тәмамлап шаһадәтнамә алу - ул әле җәннәтле булдым дигән сүз түгел. Шушында алган гыйлемнәрегез дәфтәр-конспектларыгызда түгел, ә калебләрегездә саклансын. Шул гыйлем белән гамәл кылырга, аңа нигезләнеп яшәргә кирәклеген онытмагыз. Дини гыйлемгә ия булуның, Аллаһның ихласлы, тәкъва бәндәсе булуның төп күрсәткече - ул күркәм холык, яхшы әхлак. Мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакый әйткәнчә, әхлак бетсә - дин бетәр, дин бетсә - халык бетәр. Шушы фикердән нәтиҗә ясап, үзебез дә әдәп-әхлак өлгесе булыйк, башкаларны да ислам дине кыйммәтләре белән таныштырып, якыннарыбыз, туганнарыбыз һәм кардәшләребезнең рухи дөньяларын баетыйк, туры юлны - дөнья вә ахирәт бәхетенә илтүче якты, нурлы юлны табуларына сәбәпче булыйк...

***Автор фотосы.***
***Нияз САБИРҖАНОВ***

# Йөзьяшәр мәчетнең икенче яшьлеге

**"1902 елда нигез салынган дип фаразланган иске мәчетебез бинасына шушы көннәрдә 110 ел тула. Мәчет, манарасын кискәч, озак еллар клуб, аннары мәктәп остаханәсе булып торды. 2002 елда анда каенатам Хатыйп мулла янәдән мәчет ясады. Аллаһ йорты аның исеме белән атап йөртелә.**

Моннан биш ел элек, мәчетебез икенче бинага күчкәч, бу бина ташландык хәлгә килгән иде. Хуҗасыз, җансыз әйбер тиз җимерелә, үлә. Тарихын белмәгән милләт юкка чыга. Саймә абыстай Заһриева тәкъдиме белән без биредә ислам диненә багышланган музей торгызырга карар кылдык. Менә ничә көннәр инде барыбыз да изге эш белән мәшгуль. Кем җыештыра, кем экспонатлар ташый... Без бу эшнең әһәмиятен аңлап, чын күңелдән башкарабыз, кергән бер кеше бик кызыксына, үзе дә кушыла", - дип сөйләп китте мәгариф ветераны Наилә Мөгътәсимова. "Бу музей Саймә абыстайның хыялында күптәннән йөргән булган инде. Ташкенттан контейнер-контейнер экспонатлар кайтарткан, үз кулллары белән күпләп пәрдәләр теккән, бик зур хезмәт куйган... Һич 77 яшь бирмәссең, инициативалы, гыйлемле, көчле оештыру сәләтенә ия, үз дигәненә ирешә торган әби. Безне җыеп максатны, бурычлар аңлатты. Без аңа бик рәхмәтле",- дип сүзгә кушылды икенче мәгариф ветераны Равия Хөснуллина.

Биредә борынгы әби-бабаларыбыз рухы саклана. Ислам дине тарихына багышланган экспонатлар, төрле басмадагы Коръән китаплары шактый. Авылның гүр иясе булган һәм бүгенге көндә халыкка хезмәт итүче хәзрәт-абыстайларга зур хөрмәт күрсәткәннәр, һәркайсы турында мәгълүмат туплаганнар. Халкыбызның кул эшләренә, борынгы көнкүреш әйберләренә багышланган экспозицияләр дә кызыклы. Ак яулыклы авыл апалары, бер-берсен бүлә-бүлә, һәр экспонатларның тарихы, алар белән бәйле якты истәлекләрне яңарттылар, хатирәләрне искә төшерделәр. Мәчет манарасын кисүче алыптай ирнең күтәрәмгә калып, урынында череп бетеп үлүе турында да сөйләделәр. Халык барысын да хәтерли... Күренеп тора: алар өчен биредәге һәр нәрсә кадерле, бердәнбер. Саймә абыстай борынгы Коръәнне (үзе әйтүе буенча китап 1325 елгы) кулына алды да, стенага эленгән шәҗәрә агачына карап: "Кайсыгызныкы булды икән бу?! Нәселебезгә иман керткән өчен мең рәхмәт сиңа!" -дип дога кылды.



... Фазлыгалим хәзрәт, 1940 елда, биш баласын иртеп, Донбасска чыгып китә. Бәхетне дөнья буйлап эзли. Язмыш җилләре аны Чиләбегә, аннары Ташкентка илтә. Аны зурлап әлеге шәһәрнең Карасум мәчете янына күмәләр. Дистә еллар үткәч, дүрт яшьлек чагында алып чыгып киткән кызы Саймә Заһриева-Фазлыгалимова янәдән туган туфракка кайтып, авылда мәгърифәтчелек эшен җәелдереп җибәрер дип башына да китермәгәндер ул. Гап-гади авыл йортын виноград тәлгәшләренә, чәчәкләргә күмеп, тирә-юнендә гөлбакча ясаучы, матурлык тудыручы, рухи мирасның кадерен белергә, һәркемнең тормышын мәгънәле итәргә өндәүче, иман нурлары чәчүче әбине авыл халкы үз иткән. Аның үз шәкертләре дә бар. "Балалар кайткан саен: "Әни, әйдә Ташкентка, нишләп ятасың син бу җәһәннәмдәге авылда?!" - дип аптыраталар. Мин бирегә үләр өчен кайттым. Туган җир яшәү көче бирә, кешеләргә изгелекләр эшләгән саен яшәү дәрте арта. Кешене ышаныч дигән бөек көч яшәтә. Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында!" - диде Саймә абыстай хушлашканда. Җәмәгатьчелек башлангычында төзелгән хикмәтле музейга өлеше кергән һәркемнең исемен бармакларын бөгәбөгә санап китте. Алар күп. Югары Сонда боз кузгалган. Халыкныкы халыкка хезмәт итә.

Рәсемдә: Борынгы Коръән - Саймә Заһриева-Фазлыгалимова өчен шәҗәрәнең иң кыйммәтле ядкяре.

***Автор фотосы. Алсу ДИЯР, Мамадыш районы***

# ЯҢА БИСТӘНЕҢ БЕРЕНЧЕ ТАШ МӘЧЕТЕ


**Казан шәһәрендәге Кызыл Татарстан урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан Зур таш мәчетнең тарихы, аның бүгенге хәле турында белү өчен мәчетнең имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт Сабировка мөрәҗәгать иттек.**

**- Әхмәт хәзрәт, Зур таш мәчетнең тарихы белән таныштырып үтә алмассызмы икән?**

- Бу мәчетнең тамырлары бик тирәнгә барып тоташа. Хәзерге вакытта Ак мәчет исеме белән йөртелә торган Зур таш мәчет Казандагы Яңа бистәнең төзелүе белән бәйле. XIX гасырда бөек дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре язып калдырганча, "мөселманнар читкә куыла башлагач, алар урыны-урыны белән Яңа бистәгә тупланалар". Сазлыклы җир булуга да карамастан, мөселманнар биредә бер мәхәлләгә оешып, гыйбадәтханә төзи башлыйлар. Зур таш мәчет - Яңа Татар бистәсендә салынган иң беренче мәчет дип исәпләнелә. Мөселманнар Яңа бистәгә чукындырудан, эзәрлекләүдәрдән куркып, һәм төрле хәвеф-хәтәр, янгын афәтләре килеп чыгу сәбәпле, күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Ш.Мәрҗани искәрткәнчә, 1741 елда агач мәчет, ә аннан соң аның урынына Зур таш мәчет салына. Казан өязендә көчләп чукындыру сәясәте белән кантон оешкач, Лука Канашевич Казан үзәгеннән татарларны куарга тели. Халык Яңа Татар бистәсенә күпләп күченеп килә башлагач, агач мәчеткә генә сыймый башлый. Шунлыктан, мәхәллә бу мәчетне зурайтырга, таштан салырга дигән карарга килә. Һәм аларның хыялы тормышка аша. 1801 елдан соң, Орнашбаш авылыннан (хәзерге Арча районында. - ред.) чыккан Рәкый байның матди ярдәме белән, бу мәчет зурайтылып таштан төзелә.

**- Абыйлы-энеле Тәрҗеманиләрнең мәчет тарихында гына түгел, гомумән, илебезнең дин үсешенә керткән өлешләре турында ни әйтергә мөмкин?**

- Ак мәчет Җәмигъ мәчет буларак күзаллана. Шуңа күрә аңа халык тарафыннан Зур таш мәчет дигән исем бирелә. Таш мәчет төзелеп беткәннән соң бу мәчетнең мәдрәсәсе дә эшли башлый (ул хәзерге Эш Урамында иде), күп кенә галимнәр нәкъ менә шунда белем алганнар. Мәдрәсәнең эшчәнлеге тагын да киңәю казый Кәшшафетдин Тәрҗемани (1877-1943) исеме белән бәйле: ул килгәч биредә укучылар саны тагын да күбәя. Бу турыда архив мәгълүматлары да сөйли. К.Тәрҗемани - мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең урынбасары, дөньякүләм мәшһүр дин әһеле була. Бу шәхесне аеруча билгеләп узасы килә. Ул зур белемнәре белән барлык мөселманнар арасында танyла. Инкыйлабтан соң да дини эшчәнлегенә тугры булып кала һәм дә Уфадагы Рәсәй Диния нәзарәтендә казый вазифасын башкара. Кәшшәфетдин Тәрҗемани Уфага киткәннән соң, Ак мәчеттә аның агасы Әхкәм Тәрҗемани имам вазифасын башкаручы булып кала. Кәшшафетдин хәзрәт мәгърифәтчелек эше дә алып бара. Аның кул астында дини-периодик басмалар, китаплар дөнья күрә. XX йөзнең 20 нче елларына кадәр илебезнең һәр шәһәрендә дә диярлек дини эчтәлекле газета-журналлар чыгып килсә дә, аларның эшчәнлеге инкыйлабтан соң дин кысыла башлагач туктап кала. Әмма Зур таш мәчетнең имамы совет заманына аяк атлагач та "Ислам мәҗәлләсе" дигән журнал бастырып килә. Бу журнал бөтен Россия күләмендә тарала торган була.



**- Зур таш мәчет янында ул чорда таш мәчетләр булганмы?**

- Әйе, булган. Мисал өчен, Иске Татар бистәсендәге Мәрҗани һәм Апанай мәчете төзелгән кебек Зур таш мәчет янында Иске таш мәчете дә төзелә. Иске таш мәчет Казанны яклап шәһит киткәннәрнең рухына багышлап бабаларыбызга истәлек билгесе буларак салына. Ә Җәмигъ мәчет функциясен, алда әйткәнебезчә, Зур таш мәчет үтәп килә.

**- Әлеге мәчет безнең көннәргә кадәр ничек сакланган? Хәзерге вакытта ул нинди хәлдә? Мәчетне төзекләндерү эше ни рәвешле алып барыла?**

- Зур таш мәчетнең язмышы да Россиядәге башка мәчетләрнеке белән охшаш. Совет власте елларында барлык гыйбадәтханәләр дә "үзгәртеләләр". Бигрәк тә, "үзгәртүләр" данлыклы мәчетләргә кагыла. Шул язмышка Ак мәчет тә дучар була. 1929 елда мәчет ябыла, мәхәллә кулыннан тартып алына. XX йөзнең 30 нчы елларында аның манарасы киселә, түбәсе, эчке төзелеше үзгәртелә. Шуннан соң бина буларак төрле дәүләт ихтыяҗларына файдаланыла. Шул исәптән, Казандагы ябылып барган татар мәктәпләренең берсе (35 нче мәктәп) шунда урнашкан була. Соңыннан мәчет бинасы дистә еллар буена мех берләшмәсенә карый. Анда цех оештырып тегәргә, мех эшкәртергә өйрәнгәннәр. Димәк, бабаларыбыз салган әлеге бина мәчет буларак ябылган булса да, халыкка гел файда китереп торды.

Советлар Союзы таркалып, җәмгыять тормышында үзгәртүләр башлану белән дәүләт тарафыннан тарихи гыйбадәтханә биналары халыкка кайтарыла башлый. Әмма ләкин Казан шәһәренең Яңа Татар бистәсендәге иң борынгы мәчетләрнең берсе булган Ак мәчет кайтарылмый кала. Бу мәсьәлә мөселманнарны бик борчый иде. Ниһаять, 1997 елда мәчетнең мәхәлләсе оештырылып, ул 1998 елда юридик яктан теркәлү узды. Шуның белән бергә мәчетне мөселманнарга кайтару процессы башланды. Дәүләт органнарына мөрәҗәгать ителде. Әмма бина ул чакта хосусыйлаштырылган иде. Шул сәбәпле аны дәүләт тарафыннан кайтару мөмкин түгел иде. Бу мәсьәләне хәл итү өчен мәхәллә ягыннан чишү юллары эзләнде. Моның өчен мех берләшмәсенә, "Мелита" ААҖ җитәкчелегенә мөрәҗәгать ителде. Ләкин алай да тиз генә боз кузгалмады. Чөнки бу мәсьәлә мех берләшмәсенең директорлар шурасы тарафыннан каралырга тиеш иде.

Җитәкчелек тарафыннан мәсьәлә уңай чишелә башлагач кына, мех берләшмәсенең җитәкчелеге алмашына. Үтелгән юлны кабаттан узарга туры килә. Бу юлы да мәсьәлә уңай хәл ителә дигәндә генә җитәкчелек тагын алмашына һәм мәсьәлә чишелми кала. Ниһаять, генераль директор итеп Гомәров Рәис Хафиз улы билгеләнгәннән соң "Мелита"ның директорлар шурасы хосусыйлаштырылган бинаны дәүләткә кайтарды. Һәм, элекке мәчет бинасы дәүләт милке булганнан соң, Татарстанның Министрлар Кабинеты карары белән ул мөселманнарга бирелде (барысына да Аллаһның рәхмәте яусын).

2004 елда кайтару процессы нәтиҗәсе буларак, мәчет рәсмиләштерү мәсьәләләрен узды. ТР Мәдәният министрлыгы белән аны саклау шартнамәсе төзелде. Әмма биредә капиталь ремонт булмау аркасында, бина зәгыйфь хәлдә иде, бигрәк тә аның түбә-түшәменә аеруча зур зыян килгән, түшәмнең катламнары коелу сәбәпле, анда басып торуы да хәтәр. Шуның өчен безнең алдыбызга мәчетне тулысынча төзекләндерү таләбе килеп басты. Ләкин ул вакытта мәчет үзе дә "Мелита" берләшмәсе территориясенә керү аркасында, әлеге тарихи бинага җиңел генә узып та булмый иде. Чөнки ул вакытта мәчет бинасы "Мелита" берләшмәсенең коймасы эчендә булды. Һәм мәчеткә бары тик махсус "пропуск" белән берләшмәнең җитештерү цехлары аша гына үтү мөмкин иде. Бу кыенлыкларны чишү өчен мәчет биләмәсе чикләре билгеләнде, аның тирәли коймалар корылды, аерым керү капкалары ясалды. Мәчеткә турыдан керү мөмкинлеге булдырылды. Шуннан соң, бинага тикшерелү үткәрелеп, реставрация эшләрен башкару өчен проект төзелде. Эчтәге тарихи булмаган киртәлекләр сүтелде. Бинаның фундаментлары ныгытылды. Әмма төзекләндерү эшләре җиңел генә бармый, чөнки моны тиз арада башкару өчен зур чыгымнар таләп ителә. Бүгенге көндә этаж араларында үзгәртелгән катламнарны һәм түбә-манараларны әүвәлге хәленә кайтару сорала. Алда әле тагын да колачлырак эшләр көтә...

***Фотода: инкыйлабка кадәрге Зур таш мәчет. Әңгәмәдәш - Нияз САБИРҖАНОВ***

**Ак мәчетне төзекләндерергә ярдәм итәргә теләүчеләр акчаларын түбәндәге реквизитлар аша күчерә алалар:**

**р/с 40703810700020004052**
**БИК 049205805 в АКБ «Ак Барс»**
**ИНН 1654018266**
**ОКПО 48710260**
**ОКОНХ 98700**
**Приход мечети “Ак Мечеть” Казанского мухтасибата ДУМ РТ**

# "Кол Шәриф оныклары"ның бишенче бәйгесе узды



**Чаллы мөхтәсибәтенең актив булышлыгында шәһәрдә моннан биш ел элек "Кол Шәриф оныклары" хәрәкәте туды. Анда катнашучылар ел дәвамында берничә этап аша узалар. Алар бәйге рәвешендә оештырыла. Ел саен ошбу хәрәкәткә яңа балалар тартыла тора.**

Быелгы бәйгеләрдә 80 малай катнашкан. Аларның 20 се ярымфиналга, ә 6 сы финалга үткән. 16 майда шушы егетләр арасыннан иң яхшысын сайлап алу бәйгесе булды. Ул шәһәрнең "Чишмә" исемле Халыклар дуслыгы йортында күпсанлы тамашачылар катнашында барды. Милли киемнәрдә 6 егет - 84 нче Гали Акыш лицееннан 6 "б" сыйныфы укучысы Раил Сәхәбиев, шул ук лицейдан 8 "а" сыйныфы укучылары Илдар Котдусов һәм Радик Гафиятуллин, 8 "б"дан Артур Хөсәенов, 2 нче татар гимназиясенең 7 "а" сыйныфы укучысы Булат Шәмсуров, 8 "а"дан Рөстәм Хөснуллин сәхнәгә чыктылар. Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин егетләрне җылы тәбрикләде, аларның милләтебез өчен чын шәхесләр булып үсүен теләде. Һәм шундук сынамышлар башланды. Иң башта егетләр татар халык мәкальләрен ни дәрәҗәдә белүләрен күрсәттеләр. Аннары Габдулла Тукайның "И туган тел, и матур тел, әткәм, әнкәмнең теле.-."дигән юлларына кушып, үзләре дә шушы темага шигырь юллары иҗат иттеләр. Шуннан соң викторина сорауларына җавап бирү, машина форсункасын сүтеп җыю бәйгесе булды. Егетләргә һәр дөрес җавап, җиңү өчен баллар өстәлә торды. Жюри эшләгән арада егетләр иҗат иткән видеосюжетлар, "Кол Шәриф оныклары" бәйгесендә катнашучыларның спорт ярышлары күрсәтелде. Егетләр әниләренә бүләкләр дә әзерләгәннәр иде. Аны бик җылы сүзләр белән тамашачылар алдында әниләренә тапшырдылар. Һәм менә жюри эшен тәмамлады. Хәрәкәткә нигез салучы, бүгенге көндә дә аны җитәкләүче Фәрит хәзрәт Мөдәррисов бәйгедә катнашучыларның әзерлек дәрәҗәсе югары булуын, аларның бер-берсеннән берничә балл белән генә аерылуын хәбәр итте. Әмма өстен бер балл да җиңүгә китерә. Һәм биредә нәкъ шулай булды да: көндәшләреннән берничә баллга гына өстен чыгып 13 яшьлек Раил Сәхәбиев абсолют җиңүче итеп табылды һәм бәйгенең иң дәрәҗәле призына - велосипедка ия булды.

Бәйгене тамаша итәргә егетләрнең әти-әниләре, туганнары, дуслары килгән иде. Без Раилнең әнисе Гүзәл ханым һәм бабасы Миңнефәрит ага белән сөйләштек һәм җиңүче турында өстәмә мәгълүматлар алдык. Аларның әйтүенчә, Раил лицейда "4"ле һәм "5"ле билгеләренә генә укый икән. Карате белән җитди шөгыльләнә, Россия беренчелегенә узган ярышларда катнаша. Былтыр көзен Казанда узган турнирда III урын яулаган. Һәм шулар белән бергә, Раил биш вакыт намазын да калдырмый. Менә нинди алар "Кол Шәриф оныклары" хәрәкәтендә катнашучылар.

**Рәсемнәрдә: финалда катнашучы егетләр.**

***Хәлил ШӘРИПОВ,***
***Чаллы шәһәре***

ПСИХОЛОГ КИҢӘШЕ

# *Юк-бар уйлардан котылыйм дисәң...*

**"Дин вә мәгыйшәт" газетасының 11 май санында (№ 19) "Вәсвәсә уйлардан арына алмыйм..." исеме астында укучыбызның соравына Татарстанның көнчыгыш төбәге казые Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов тарафыннан җавап бирелгән иде. Әлеге мәсьәләгә карата ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы, психология фәннәре кандидаты Камил Насыйбуллинның да фикерен белергә булдык:**

- Иң элек, сез вәсвәсә уйларга карата гомуми карашыгызны үзгәртергә тиеш. Иң мөһиме - алардан курыкмый башларга кирәк, чөнки нәкъ менә курку сезнең белән идарә итәргә мөмкинлек тудыра да инде. Кешенең башы шулай "көйләнгән": ул һәрвакыт уйлануда. Сезгә нинди дә булса берәр әйбер турында уйламаска кушсалар да, сез барыбер уйларыгызны уйламавыгыз турында уйлаячаксыз (тавтология өчен гафу үтенәм). Кешенең танып белү процессларының (сизү, кабул итү, хәтердә тоту, фикер йөртү һәм күзаллау) игътибардан башка мөмкин булмавын истә тотарга кирәк, игътибарлылык аларны озатып бара һәм ул аларның кайсысы сезнең аңыгызда өстенлек итүе өчен җавап бирә. Эш шунда: дога кылучы кеше игътибарын шушы процессны үтәүгә юнәлтә, аның башында башка уйларга урын калмый.

Бу мисалдан шуны аңларга кирәк: сезне җәфалаучы уйларны контрольгә алырга мөмкин. Игътибарыгызны тупларга өйрәнегез. Моның өчен теләсә нинди текст язылган бер битне алып, үз алдыгызга, мәсәлән, "и" хәрефләрен сызып ташларга, "а" хәрефләренең асларына сызарга дигән максат куегыз.

Тора бара бу күнегүне, шулар янына хәрефләр өстәп яки алдан уйланганнарын түгәрәк эченә алып, тагын да катлауландырырга була. Бу гап-гади "эш"не башкару өчен үзегезгә көн саен ярты сәгать вакыт бүлеп куйсагыз, сез игътибарлылыгызны арттыра алачаксыз һәм бу дога кылганда зиһенегезнең бер урынга тупланып торуына китерәчәк. Интернетта Б. Бурдон тестын (Корректурная проба Бурдона) эзләп тапсагыз, ул сезгә игътибарыгызны арттыру өчен зур ярдәмлек булып хезмәт итәчәк.

Вәсвәсә уйлар белән көрәштә икенче ысул - аларны тулы контроль астына алу. Сезнең моңа охшаш уйлардан качарга омтылуыгыз бернинди нәтиҗәгә китермәячәген аңлау мәслихәт. Бу илебезнең мәшһүр психологы Б.В. Зейгарник тасвирлаган һәм аның исеме белән аталган йогынты (эффект) хисабына барлыкка килә.


Бу төр йогынтының төп асылы шунда: һәр тәмамланмаган эш, шул исәптән уйлар да, ахыргы нокта куелганчыга кадәр кешенең исеннән чыкмаячак. Шулай итеп, сезгә үз уйларыгызны курыкмыйча анализлый башларга кирәк. Сезне борчый торган теләсә нинди бер фикергә "ябышыгыз" да, шуның турында ныклап уйлый башлагыз. Башта бу куркыныч булып тоелырга мөмкин, чөнки сезнең әхлак принципларыгыз аларны кабул итми, дөресрәге, моны күңелегездән кысрыклап чыгара.

Иң мөһиме - курыкмаска кирәк, чөнки башка төрле уйлар килергә мөмкин. Шунысын да истә тотыгыз: сез нинди генә уйларга иярсәгез дә, тыелган гамәлләр башкармыйсыз бит. Шундый уйларның берсен "тотып" анализлый башлауга ук, сез аның көчен югалта баруын тоячаксыз.




## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 26.05.12 | 2:44 | 4:14 | 13:02 | 18:27 | 21:09 | 22:39 |
| Якшәмбе | 27.05.12 | 2:42 | 4:12 | 13:02 | 18:27 | 21:10 | 22:40 |
| Дүшәмбе | 28.05.12 | 2:41 | 4:11 | 13:02 | 18:29 | 21:12 | 22:42 |
| Сишәмбе | 29.05.12 | 2:40 | 4:10 | 13:02 | 18:29 | 21:13 | 22:43 |
| Чәршәмбе | 30.05.12 | 2:39 | 4:09 | 13:02 | 18:31 | 21:15 | 22:45 |
| Пәнҗешәмбе | 31.05.12 | 2:38 | 4:08 | 13:02 | 18:31 | 21:16 | 22:46 |
| Җомга | 1.06.12 | 2:37 | 4:07 | 13:02 | 18:32 | 21:17 | 22:47 |
| Шимбә | 2.06.12 | 2:36 | 4:06 | 13:02 | 18:33 | 21:19 | 22:49 |




**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №21 (138) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-535.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 24 май көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).